ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮЛЛЕ-КИМЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

СОВЕТ КУЛЛЕ-КИМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422742 Республика Татарстан Атнинский район с. Кулле-Кими. Тел. 3-53-40

**КАРАР №82**

Күлле-Киме авылы 29 сентябрь 2023 ел

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, “Коррупциягә каршы тору турында ” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 29.03.2011 № 18 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының “Күлле-Киме авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә (29.08.2011№26, от 24.11.2011 №29, от 23.03.2012 №33, от 18.09.2012 №43, от 03.12.2012 №47, от 08.10.2013 №64, от 23.03.2015 №101, от 18.12.2015 №12, от 02.05.2016 №27, от 25.04.2017 №47, от 28.08.2017 №59, от 25.04.2018 №74, от 21.12.2018 №88, от 22.05.2019 №97, от 03.10.2019 №107, от 20.12.2019 №117, от 09.03.2020 №125, от 30.10.2020№8, от 29.01.2021 №16, от 01.09.2021 №32, от 18.07.2022 №50, от 09.02.2023 №66 үзгәрешләре белән).

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге www.pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы: Гәрәев Х.Х.

Кушымта
Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советының
29.09.2023 ел № 82 карарына

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. **28 статьяның 2.4 пунктындагы 3 абзацта** «, акцияләр» сүзен төшереп калдырырга;

2. **28 статьяның 2.6 пунктын** түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга «,«Коррупциягә каршы тору турында» гы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләре нигезендә, әгәр федераль конституцион законнарда, федераль законнарда башкасы каралмаган булса, аларга бәйле булмаган шартлар аркасында мондый тыюлар, чикләүләр һәм бурычлар бозылган очраклардан тыш”;

3. **28 статьяның 2.9 пунктын** үз көчен югалткан дип танырга;

4. **38 статьяның 1 пунктына** түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:
“12. Депутатнын муниципаль берәмлек вәкиллекле органының барлык утырышларында алты ай рәттән җитди сәбәпләрсез булмавы.»;

5. **49 статьяның 1 пунктындагы 2 абзацында** «Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 97.1 статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр; «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» 2005 елның 18 маендагы 51-ФЗ номерлы Федераль законның 82.1 статьясы, «муниципаль районның сайлау комиссиясе;» сүзләрен төшереп калдырырга;

6. **49 статьяның 2 пунктындагы 1 пунктчасында** «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» Федераль законның 82.1 статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

7. **49 статьяның 3 пунктын** түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:
“3. Җирлек советы территориаль сайлау комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә җирлек сайлау комиссиясе әгъзаларының гомуми санының яртысын билгеләргә тиеш.”;

8. **66 статьяның 9 пунктында** «һәм мәдәният» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе халыклары (алга таба - мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре)» сүзләрен өстәргә.